**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ АТАБАЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422635 Лаишевский район,
село Атабаево,ул.Молодежная , д.1
тел: 8(84378)-4-87-41
факс: 8(84378)4-87-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422635 Лаеш районы, Атабай авылы
ул.Яшьлэр урамы, 1нче йорт
тел: 8(84378)-4-87-41
факс: 8(84378)-4-87-41

**2024 елның 27мае** **194 номер**

## КАРАР

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2014елның 13 ноябрендәге 103 номерлы Атабай авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 13 ноябрендәге 103 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге советы карарына (20.05.2015 № 132, 09.10.2015 N 6, 17.10.2018 N 105, 02.11.2018 N 115, 08.10.2020 N 10, 28.11.2022 N111 номер үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацны:
"Салым ташламасына хокуклы затлар салым органына ташламалар бирү турында гариза, шулай ук салым ташламасына хокукны раслый торган документлар тапшыра."
яңа редакциядә бәян итәргә:

"Салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гаризаны үз сайлавы буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документлар тапшырырга хокуклы."

1.2. 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле 3.4 пунктча өстәргә:
«3.4. Салым ташламасына хокуклы салым түләүчеләр категорияләре Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясында билгеләнгән.»

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Атабай**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Л.Р.Хәлилова**